КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 8 май г.Казань № 679

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү буенча мәгариф программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 ел, 18 гыйнвар, 9 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәктәпкәчә белем бирү буенча мәгариф программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында» 2007 ел, 18 гыйнвар, 9 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 апрель, 167 нче; 2007 ел, 5 октябрь, 533 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче; 2008 ел, 17 март, 171 нче; 2008 ел, 25 июнь, 429 нчы; 2009 ел, 27 март, 179 нчы; 2010 ел, 1 февраль, 49 нчы; 2012 ел, 15 май, 376 нчы; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 31 август, 620 нче; 2014 ел, 21 май, 338 нче; 2017 ел, 24 март, 179 нчы; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2021 ел, 10 апрель, 236 нчы; 2024 ел, 1 февраль, 53 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның өченче абзацында «Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге бүлекләре яки «Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ» сүзләрен «Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү буенча мәгариф программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләүгә мөрәҗәгать итү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

3 пунктта «Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге бүлекләре» сүзләрен «Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» дәүләт казна

учреждениесе бүлекләре (алга таба – Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге бүлекләре)» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«оештыру-хокук рәвешенә карамастан теләсә кайсы типтагы мәгариф оешмасында (өстәмә белем бирү мәгариф оешмасыннан тыш) көндезге формада белем алучы 18 яшьтән 23 яшькә кадәрге (никахлашмаган) балалар;»;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Компенсация Россия Федерациясе гражданнарына, чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 71 пункт өстәргә:

«7[1]. Компенсация гариза бирүченең яшәү урыны буенча йә аның тору урыны буенча (Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны булмаган очракта), ә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлү белән расланган яшәү урыны һәм тору урыны булмаган гариза бирүчеләр өчен Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программасын гамәлгә ашыра, бала йөри торган мәгариф оешмасының урнашу урыны буенча Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге бүлеге тарафыннан билгеләнә.

8, 8[1] һәм 9 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Компенсация алу өчен гариза бирүче яки аның законлы вәкиле яисә гариза бирүче тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән зат түбәндәгеләрне тапшыра:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясенең тиешле субъекты территориясендәге дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация түләү» дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтүнең бердәм стандартын раслау турында» 2023 елның 27 маендагы 829 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясенең тиешле субъекты территориясендәге дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмаларында баланы карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация түләү» дәүләт хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтүнең бердәм стандартына теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча компенсация билгеләү турында гариза (алга таба – гариза);

гариза бирүченең шәхесен таныклый торган документ (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә);

баланың законлы вәкиле ваклэтләрен раслый торган документ (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә);

чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала (балалар) туу турында таныклык күчермәсен һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе күчермәсен (тиешле актның язуы чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан теркәлгән очракта);

әлеге Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә гариза бирүченең гаилә составында исәпкә алынган, компенсация билгеләнә торган баладан (балалардан) иртәрәк туган, чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала (балалар) туу турында таныклык күчермәсе һәм аның рус теленә нотариаль таныкланган тәрҗемәсе күчермәсе (тиешле актның язуы чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан

теркәлгән очракта);

гариза бирүченең балигъ булган баласының (балаларының) уку урыныннан оештыру-хокук рәвешенә карамастан теләсә кайсы типтагы мәгариф оешмасында (өстәмә белем бирү мәгариф оешмасыннан тыш) көндезге формада белем алуын раслый торган белешмә кәгазе (мондый балалар гаиләдә булган очракта);

никахны теркәү турында белешмәләрне раслый торган, чит дәүләтләрнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән документлар һәм рус теленә тәрҗемәсе (әгәр никах чит дәүләт территориясендә теркәлгән булса);

никахны таркату турында белешмәләрне раслый торган, чит дәүләтләрнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән документлар һәм рус теленә тәрҗемәсе (әгәр никах чит дәүләт территориясендә таркалган булса);

гариза ышанычлы зат тарафыннан бирелсә, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә.

Әлеге документлар, төп нөсхәләрен күрсәтеп, күчермәләр рәвешендә яисә нотариаль таныкланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла. Документларның күчермәләре, аларның төп нөсхәләренә туры килүен тикшергәннән соң (документларның нотариаль таныкланган күчермәләреннән тыш), документларны кабул итүче зат тарафыннан таныклана.

Гариза бирүче гаризаны, шулай ук кирәкле документларны түбәндәге ысулларның берсе белән җибәрә:

турыдан-туры (шәхсән) кәгазьдә;

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – Бердәм портал) яки «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып (алга таба – төбәк порталы), электрон рәвештә;

почта аша.

Гариза электрон формада бирелгәндә гариза бирүченең һәм баланың (балаларның) җенесе, индивидуаль шәхси счетның иминият номеры (алга таба – СНИЛС), гражданлыгы турында юлларны тутыру мәҗбүри характерга ия.

Бердәм порталда яки төбәк порталында тутырылган гариза, әлеге пунктта күрсәтелгән документларның теркәлгән электрон рәвешләре белән бергә, гариза бирүче тарафыннан Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге бүлегенә җибәрелә. «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында авторизацияләнгәндә гариза аны бирүченең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

$8^1$. Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге бүлеге ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып электрон рәвештә, компенсация билгеләү турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге белешмәләрне ала:

бала (балалар) тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

баланы (балаларны) тиешле мәгариф оешмасына урнаштыру турында

шартнамә төзегән зат турында;

мәгариф оешмасында бала карап торган һәм караган өчен түләү квитанциясендә күрсәтелгән табель номеры турында;

балага (балаларга) карата ата-аналарны (законлы вәкилләрне) (яки аларның берсен) ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү турында;

балага (балаларга) карата ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) (яки берсенең) ата-ана хокукларын чикләү турында;

баланың (балаларның) гомеренә яисә сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда ата-аналардан (законлы вәкилләреннән) (яисә аларның берсеннән) алу турында;

гаиләдә яшәүче баланың (балаларның) ата-аналары (законлы вәкилләре) арасында никахлашу (никахны таркату) турында;

гаиләдә яшәүче балага (балаларга) карата ата (ана) булуны билгеләү яки дәгъвалау турында;

фамилиясен, исемен яисә атасының исемен үзгәрткән гаиләдә яшәүче ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) яки баланың (балаларның) фамилиясен, исемен яки атасының исемен үзгәртү турында;

гаиләдә яшәүче балага (балаларга) опека (попечительлек) билгеләү турында;

үлемне дәүләт теркәвенә алу турында;

Компенсация алу максатларында гариза бирүче яки аның тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән зат үз инициативасы белән Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге бүлегенә әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр бирелгән документларны, шул исәптән электрон документ рәвешендәге документларны тапшырырга хокуклы.

9. Гаризага гариза бирүченең һәм баланың (балаларның) җенесе, СНИЛСы, гражданлыгы турында мәгълүматлар кертү шарты белән компенсация билгеләү срогы гариза һәм компенсация билгеләү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән алып иң күбе алты эш көне тәшкил итә.

Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге бүлегенә турыдан-туры бирелгән гаризада гариза бирүченең һәм баланың (балаларның) җенесе, СНИЛСы, гражданлыгы турында мәгълүматлар булмаган очракта, гариза бирүчегә гаризаны карап тикшерү срогы ведомствоара рәсми сорауларны гамәлгә ашыру өчен кирәкле чорга озайтылу турында хәбәр ителә, әмма шул ук вакытта гаризаны карап тикшерү срогы гариза һәм компенсация билгеләү өчен кирәкле документлар теркәлгән көннән алып 11 эш көненнән артмаска тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле $9^1$ – $9^3$ пунктларны өстәргә:

«$9^1$. Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр:

гариза һәм компенсация билгеләү өчен кирәкле документлар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләр бозылып тапшырылган, шул исәптән:

гариза аны бирүче исеменнән эш итәргә вәкаләтләре булмаган зат тарафыннан бирелгән;

гариза бирүче тарафыннан компенсация билгеләү өчен кирәкле һәм әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар тулы булмаган комплектта

тапшырылган;

гариза бирүче тарафыннан электрон формада гариза бирүченең һәм баланың (балаларның) җенесе, СНИЛСы һәм гражданлыгы турында юллар тутырылмаган;

компенсация сорап мөрәҗәгать итү датасына тапшырылган документларның гамәлдә булу срогы чыккан;

гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларда Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә расланмаган текстны бозып төзәтүләр һәм төзәтмәләр бар;

тапшырылган документларда компенсация билгеләү өчен мондый документлардагы мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмдә файдаланырга мөмкинлек бирми торган бозыклыклар бар;

тапшырылган документлар әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән электрон рәвештә компенсация билгеләүгә карата билгеләнгән таләпләргә туры килми.

$9^2$. Компенсация билгеләүне туктатып тору өчен нигез – документларны яки ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында гариза бирүче тарафыннан күрсәтелгән мәгълүматны тикшерергә комачаулый торган хәлләрне өстәмә тикшерү кирәклеге барлыкка килү.

Гариза бирүче компенсация билгеләүне туктатып тору турында хәбәрнамә алынганнан соң биш эш көне эчендә Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге бүлегенә (әлеге Нигезләмәнең 8 пунктында күрсәтелгән ысул белән) компенсация билгеләү өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне җибәрә.

Компенсация билгеләү өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр билгеләнгән срок эчендә тапшырылмаган очракта, гариза бирүчегә компенсация билгеләүдән баш тарту турында җибәрелә. Шул ук вакытта гариза бирүченең кабат гариза бирү хокукы саклана.

$9^3$. Компенсация билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр:

гариза биргән зат әлеге Нигезләмәнең 7 пунктындагы беренче абзацында билгеләнгән затлар даирәсенә керми;

тапшырылган белешмәләр һәм (яки) документлар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында алынган белешмәләргә туры килми;

тапшырылган документлар үз формасы яки эчтәлеге буенча Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары яки башка норматив хокукый актлары таләпләренә туры килми;

гариза бирүче гаризаны кире алу. Гаризаны кире алу гариза бирүче Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гамәлгә ашырыла;

гариза бирүче тарафыннан тулы булмаган һәм (яки) белә торып дөрес булмаган белешмәләр бирү.»;

13 пунктта «1» санын «3» санына алмаштырырга;

14 – 16 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

17 һәм 18 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) аның заявкалары буенча

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре чикләрендә җиткерә.

18. Министрлык финанслауның иң чик күләмнәрен алга таба гражданнарның кредит оешмаларында үзләре ачкан шәхси счетларына яисә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле шартнамәләр (контрактлар) төзелгән почта элемтәсе оешмаларына күчерү өчен «Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» дәүләт казна учреждениесенә кадәр җиткерә.»;

19 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

23 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

25 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

29 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына 2026 елның 1 августына кадәр әлеге карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле «Ярдәм» социаль яклау органнарының мәгълүмат системасын эшләп бетерүне тәэмин итәргә.

3. Бу карарның 1 пункты 2026 елның 1 августыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин